**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «____» ____________20__ г. №______

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен ябу турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьялары, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 өлеше нигезендә, 2023 елның 14 июнендәге 14 июнендәге «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен ябу турында карар кабул итү нәтиҗәләрен эксперт бәяләве нигезендә, 2023 елның 14 маендагы Кибәч авыл җирлеге гражданнары җыелышы беркетмәсе, «Мәгариф» тармагы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 422793, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кибәч ав., Пионер урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен (алга таба - Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе) ябарга.

2. Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу комиссия составын расларга (1 нче кушымта).

3. Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу буенча Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә чаралар планын расларга (2 нче кушымта).

4. Ликвидация комиссиясенә Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябуны Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин итәргә һәм кирәкле гамәлләрне шул исәптән:

- әлеге карар кабул ителгән көннән соң законда билгеләнгән срокларда Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу турында язма формада вәкаләтле дәүләт органына әлеге карарны кертеп, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хәбәр итәргә;

- әлеге карар кабул ителгәннән соң, законда билгеләнгән срокларда Пенсия фондына һәм Социаль иминият фондына Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе ябулуы турында хәбәр итәргә;

- Юридик затны дәүләт теркәве турында белешмәләр бастырыла торган матбугат органнарында Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу турында, кредиторлар таләпләрен белдерүнең тәртибе һәм срогы турында хәбәрнамә бастырып чыгарырга:

- кредиторларга юридик затны юкка чыгару турында язмача хәбәр итәргә;

- арадаш ликвидация балансы төзергә һәм гамәлгә куючыга раслауга бирергә;

- учреждение эшләре белән идарә итү буенча барлык вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга;

- барлык органнарда һәм оешмаларда юкка чыгарыла торган учреждение исеменнән чыгыш ясарга.

5. Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу турында тиешле тәртиптә хезмәткәрләргә хезмәт шартлары үзгәрү турында хәбәр итәргә;

6. Әлеге карар кабул ителгән һәм учреждениенең ликвидация комиссиясен билгеләгән вакыттан алып РФ Гражданлык кодексының 62 статьясындагы 3 пункты нигезендә учреждениенең эшләре белән идарә итү буенча барлык вәкаләтләр, аның финанс-хуҗалык эшчәнлеге ликвидация чорында күчә дип билгеләргә.

7. «Вперед («Алга») район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе укучыларын алга таба укытуга бәйле оештыру чаралары уздырырга.

9. Ликвидация комиссиясе рәисе урынбасары А.С. Шәйхисламовка оештыручы һәм ликвидация комиссиясе мәнфәгатьләрен якларга вәкаләт бирергә:

- Татарстан Республикасы буенча 18 нче федераль салым хезмәтендә имзаны алу, гаризалар бирү һәм документлар алу хокукы белән;

- Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбен ябу турында белдерүләрне (хәбәрнамәләрне) бастыруга гаризалар һәм документлар бирү хокукы белән;

10. Сократить штатные единицы МБОУ «Кибячинская ООШ», а именно: педагогический состав в количестве штатных единиц 6,94 ставки, прочий персонал: 1 ставка «Сторож», 3 ставки «Машинист (кочегар) котельной 6 разряда», 1 ставка «Уборщик производственных и служебных помещений», 0,25 ставки «Библиотекарь», 1 ставка «Повар 4- 5 разряда», 0,5 ставки «Рабочий по комплексному обслуживанию зданий»

11. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхисламовка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе В.И.Никитин

Башкаручы: М.А.Харитонова
тел. 8/843/673-03-54

Кушымта № 1
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
«___» _________2023 ел № ___

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы “Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалының ликвидация комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

Шәйхесламов Азат Сөләйманович - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Комиссия әгъзәлары:

Харитонова Марина Алексеевна – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы;

Иванова Татьяна Алексеевна – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе башлыгы (килешү буенча);

Шатаева Елена Николаевна – Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан оешмасы Питрәч районы профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча).

Дәүләтханов Илназ Ринатович - мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча);

Барматунов Михаил Григорьевич - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кибәч төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча)